СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**2019 ел, « 18 » апрель** **№ 246**

**Арча муниципаль районында мемориаль такталар кую тәртибе турында Нигезләмә раслау турында**

Мемориаль такталарны проектлауны, эшләүне һәм куюны тәртипкә китерү, тарихта билгеле вакыйгаларны һәм казанышлары белән Арча муниципаль районына, Татарстан Республикасына һәм Россия Федерациясенә файда китергән шәхесләрне мәңгеләштерү турында карар кабул итү критерийларын билгеләү максатында, «Татарстан Республикасында мемориаль такталар кую тәртибе турында Нигезләмә раслау турында» 2002 елның 01 апрелендәге 163 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карарына нигезләнеп, Арча район Советы **карар чыгарды:**

1. Кушымта буенча Арча муниципаль районында мемориаль такталар кую тәртибе турында Нигезләмәне расларга.
2. Арча муниципаль районы Башкарма комитетына Мемориаль такталар буенча Комиссия турында Нигезләмә эшләргә, аның составын билгеләргә һәм расларга.
3. Авыл һәм шәһәр җирле үздарә органнарына әлеге карар белән расланган Арча муниципаль районында мемориаль такталар кую тәртибе турында Нигезләмәгә таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга һәм Интернет телкоммуникация челтәрендә Татарсатн Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының социаль мәсьләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Арча муниципаль районы башлыгы И.Г.Нуриев

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ

Кушымта
Арча район Советының
2019 елның «18» апрель
246 номерлы карарына

**Арча муниципаль районында мемориаль такталар кую тәртибе турында Нигезләмә**

**I. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Мемориаль такта – фән һәм техника, мәдәният, сәнгать һәм мәгариф үсешенә, гражданнарның сәламәтлеген, гомерен һәм хокукларын саклауга зур өлеш керткән, хәри батырлыклар кылган һәм Ватан алдындагы казанышлары өчен күренекле шәхесләрнең истәлеген, Арча муниципаль районы, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе тарихындагы әһәмиятле тарихи вакыйгаларны һәм даталарны мәңгеләштерүне күздә тоткан тарихи һәйкәл булмаган (сәнгать әһәмиятенә ия булган һәм монументаль сәнгать объектларына крегән очраклардан тыш) истәлек билгесен тәшкил итүче монументаль сәнгатьнең бер төре.

Биналарда, корылмаларда урнаштырыла торган һәм әлеге Нигезләмә белән каралган вакыйга һәм даталарны мәңгеләштерү белән бәйле булмаган башка мәгълүмат билгеләре (такталар) мемориаль булмый.

1.2. Мемориаль такталар тарихи вакыйгалар барган яки күренекле кешеләр яшәгән биналарның, корылмаларның алгы якларында, кайбер очракларда бинаның эчке бизәлешендә һәм истәлеле урыннарда урнаштырыла, шулай ук урамнарны күренекле кешеләр яки тарихи вакыйгалар истәлегенә атаганда.

1.3. Бинада, корылмада мемориаль такта әлеге бинага, корылмага милек хокукында, хуҗалык алып баруы яки оператив идарә итү формасында ия булган юридик яки физик зат ризалыгы белән урнаштырыла.

1.4. Мемориаль такталарның тексты Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә – русча һәм татарча язылырга тиеш.

1.5. Мемориаль такта кую белән Россия Федерациясе гражданнары, шулай ук башка дәүләтләр гражданнарының истәлеге мәңгеләштерелергә мөмкин.

1.6. Мемориаль такта кую Арча муниципаль районы «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе тарафыннан бирелгән материаллар нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә башкарыла.

1.7. Мемориаль такталарны проектлау, эшләү һәм кую буенча эшләр заказчысы булып Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

1.8. Мемориаль такта кую турында Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карары Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырыла.

**II. Гражданнар яки вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү өчен нигезләр**

2.1. Мемориаль такта кую турында карар кабул итү өчен нигез булып тора:

вакыйганың Арча мунииңпаль районы, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе өчен мөһим булуы;

дәүләт, җәмәгать, сәяси, хәрби, җитештерү эшчәнлегендә, фән, техника, әдәбият, сәнгать, мәдәният, спорт өлкәләрендә танылган казанышлар булу, шулай ук шәхеснең Арча муниципаль районы, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенә файда китергән, аерым өлкәгә керткән өлеше, әлеге казанышларны Арча муниципаль районы халкы таныган очракларда.

2.2 Мемориаль такта куелырга мөмкин:

төрле өлкәләр үсешенә зур өлеш керткән һәм дәүләт бүләкләренә ия булган гражданнар истәлегенә;

Арча муниципаль районы, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе файдасына батырлыклар һәм башка танылган гамәлләр кылган гражданнар истәлегенә.

### III. Мемориаль такталарны кую тәртибе

3.1. Вакыйганың яки исеме мәңгеләштереләсе затның тарихи һәм мәдәни әһәмиятен дөрес бәяләү максатында мемориаль такта исеме мәңгеләштереләсе затның вафатыннан соң 1 елдан да иртәрәк, мәңгеләштереләсе вакыйгадан соң 5 елдан да иртәрәк куела алмый.

3.2. Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Геройларына, Дан орденының тулы кавалерларына мемориаль такталар аларның вафатыннан соң алар соңгы елларда яшәгән йортта яки лаеклы ялга (отставкага) чыгар алдыннан эшләгән оешма бинасына куела.

### IV. Мемориаль тактаның тышкы кыяфәтенә таләпләр:

4.1. Мемориаль такталар бары тик нык материаллардан (мәрмәр, гранит, чуен, бакыр һәм башка металлардан) гына эшләнә.

4.2. Мемориаль тактадагы текст кыска һәм ачык формада бирелергә тиеш һәм исеме мемориаль тактада мәңгеләштерелгән затның яшәү дәверендә ирешкән казанышлары (эшчәнлеге) турында мәглүмат бирергә тиеш.

4.3. Мемориаль такта текстында әлеге тактада исеме мәңгеләштерелгән затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) күрсәтелгән булырга тиеш.

4.4. Мемориаль такталар композициясенә, тексттан тыш, портрет рәсемнәре, бизәлеш элементлары кертелергә мөмкин.

### V. Мемориаль такта кую турында үтенеч бирү тәртибе

5.1. Мемориаль такта кую инициаторы (алга таба – инициатор) булып дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, милек формасына карамастан оешмалар, шулай ук 10 кешедән дә ким булмаган гражданнар төркеме чыгыш ясарга мөмкин.

5.2. Мемориаль такта урнаштыру өчен инициатор Арча муниципаль районы «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесенә түбәндәге документларны тапшыра:

мемориаль такта урнаштыру кирәклеген тулы итеп дәлилләгән гариза

(үтенеч);

рәсми документларга нигезләнгән тулы биографик яки тарихи белешмә;

мәңгеләштереләсе вакыйга яки исеме мәңгеләштереләсе затның казанышларының дөреслеген дәлилләүче архив документлары яки башка документлар;

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белгечләре тарафыннан расланган, тиешле телләрдә язылган мемориаль такта тексты проекты;

мемориаль такта эскизы;

мемориаль такта куелырга тиешле урын турында мәгълүмат (мемориаль такта куеласы урынны күрсәтеп, бинаның алгы ягының, эчке бизәлешенең фотосы);

исеме мәңгеләштереләсе затның әлеге бинада яшәгән вакытлары күрсәтелгән торак-файдалану предприятиеләреннән алынган документлар;

йорт (бина) кулланучының яки милекченең мемориаль такта куюга рөхсәте;

мемориаль тактаны проектлау, эшләү һәм куюга чыгымнар сметасы һәм финанслау чыганаклары турында мәгълүмат;

мемориаль тактаны проектлау, эшләү, кую һәм ачу тантанасы чыгымнарын түләү турында инициатордан гарантия хаты;

мемориаль такта шәһәр, авыл җирлегендә куелган очракта җирлекнең башкарма органы һәм әлеге җирлек урнашкан муниципаль район башлыгы белән килештерү.

5.3. Әлеге карарның 5.2 пунктында күрсәтелгән, инициатор тарафыннан тапшырылган документлар Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы мемориаль такталар буенча Комиссия (алга таба – Комиссия) тарафыннан карала.

5.4. Комиссия турында Нигезләмә һәм аның составы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

Комиссия составына Арча муниципаль районы Башкарма комитеты, Арча район Советының социаль мәсьләләр буенча даими комиссиясе (килешү буенча), Арча муниципаль районы «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе вәкилләре, мемориаль такта урнаштырыласы авыл җирлеге, шәһәр җирлеге башлыклары (килешү буенча), иҗади һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре керә. Кирәк булган очракларда Комиссия үз эшчәнлегенә төрле оешма һәм ведомство белгечләрен җәлеп итәргә мөмкин.

5.5. Комиссия кергән документларны тикшерә һәм документлар кергән көннән соң 1 ай эчендә мемориаль такта урнаштыру мөмкинлеге турында карар чыгара.

5.6. Комиссия мемориаль такта урнаштыру турында уңай карар кабул иткән очракта Арча муниципаль районы «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе әлеге карар чыкканнан соң 1 ай эчендә Арча муниципалрайоны башкарма комитеты исеменә карар проекты җибәрә.

Проектка беркетелә:

комиссия утырышы беркетмәсе яки беркетмәдән өземтә:

мәңгеләштерәсе вакыйга яки зат турында гомуми мәгълүмат;
мемориаль такта урнаштырыласы урын турында мәгълүмат;
мемориаль тактаны проектлау, эшләү һәм кую буенча финанс чыганаклары турында мәгълүмат;
мемориаль такта урнаштырыласы территориядәге авыл, шәһәр җирлеге башлыгы белән килештерү.
Комиссия тарафыннан тискәре карар кабул ителгән очракта инициаторга бу турыда әлеге карар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә хәбәр ителә.

## VI. Мемориаль такталарны кую, карап тоту һәм исәпкә алу тәртибе

6.1. Мемориаль такталарның зурлыгы һәм кую урыны Комиссия утырышында карала һәм килештерелә. Мемориаль такта кую биналар, корылмалар һәм инженер челтәрләр конструкцияләренә зыян салмаска тиеш.
6.2. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының мемориаль такта кую турында карарын кабул иткәннән соң инициатор аны әзерләү һәм кую чараларын гамәлгә ашыра.
6.3. Кирәк булган очракта (бина, корылманың алгы ягы канәгатьләнерлек хәлдә булмаганда) инициатор мемориаль тактаны ачу тантанасын үткәргәнче бина, корылманың алгы ягына төзекләндерү үткәрә.
6.4. Торак һәм торак булмаган йортлар (күпфатирлы торак йортлардан тыш) биналарына куелган мемориаль такталарны инициатор бинаның милекчесе (аннан файдаланучы) балансына тапшыра яки аларны куйган оешма балансына кабул ителә.
Күпфатирлы торак йортлар биналарына куелган мемориаль такталарны инициаторлар территорияләрендә әлеге күпфатирлы торак йортлар урнашкан авыл, шәһәр җирлегенең Башкарма комитеты балансына тапшыра яки аларны куйган оешма балансына кабул ителә.
6.5. Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм балансларында мемориаль такталар булган оешмалар аларны саклау һәм агымдагы карап тоту буенча чаралар күрә.
6.6. Мемориаль такталарның исәбен алу һәм аларның торышын контрольдә тоту территорияләрендә мөһим тарихи вакыйгалар булган, күренекле шәхесләр яшәгән яки эшләгән биналар, корылмалар һәм истәлекле урыннар урнашкан авыл, шәһәр җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.
6.7. Мемориаль тактаны алу турында карар (аны үзгәртеп кору таләп ителгән яки такта куелган бинада төзекләндерү–үзгәртеп кору эшләре үткәрелә торган очраклардан тыш) Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә.

## VII. Мемориаль такталарны проектлау, эшләү һәм кую буенча чыгымнарны финанслау

7.1. Мемориаль такталарны проектлау, эшләү һәм кую буенча чыгымнарын үтенеч белән чыккан як күтәрә.
7.2. Иҗтимагый әһәмияткә ия булган монументаль сәнгать өлкәсендә иҗади проектларның югары сәнгать дәрәҗәсен тәэмин итү максатында

мемориаль такта эшләүгә муниципаль сатып алулар Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла һәм тулысынча яки өлешчә җирле бюджет акчалары хисабына финанслана.

## VIII. Мемориаль такталарны саклау һәм куллану кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылык

8.1. Мемориаль такталарның сакланышын тәэмин итү кагыйдәләрен бозуда гаепле затлар гамәлдәге законнар нигезендә җавап тота.

8.2. Куелган мемориаль тактага зыян китергән затлар аны элеккеге рәвешенә кире кайтарырга, әгәр бу мөмкин булмаса, гамәлдәге законнар нигезендә китергән зыянны капларга тиеш.